# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ МӘТӘСКӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

**утыз бишенче утырыш дүртенче чакырылыш**

**29 июль 2024 ел** **№123** **Олы Мәтәскә авылы**

Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 2023 елның 11 ноябрендәге 116 номерлы «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының 2024 елның 20 мартындагы 09/13-09/1229 номерлы хатын, Теләче районы прокурорының 16.03.2024 №20037-396-24/20920037 протестын карап, Россия Федерациясе Салым кодексы нигезендә,Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Теләче муниципаль районы Олы Мәтәскә авыл җирлеге Советының 2023 елның 11 ноябрендәге 106 номерлы «Җир салымы турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Җир салымының салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

А) җир кишәрлекләренә карата 1,5 процент:

авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә авыл хуҗалыгы җитештерүе өчен файдаланыла торган торак пунктларда авыл хуҗалыгы файдалануы зоналары составындагы җирләргә кертелгән;

торак фонды һәм (яисә) торак-коммуналь комплексы инженерлык инфраструктурасы объектлары белән белән биләнгән(торак фондына һәм (яисә) торак-коммуналь комплексы инженерлык инфраструктурасы объектларына карамаган күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлешеннән тыш яисә торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән)(эшкуарлык эшчәнлегендә кулланыла торган индивидуаль торак төзелеше өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләреннән тыш );»

шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, бакчачылык яисә яшелчәчелек өчен сатып алынган (бирелгән) эшкуарлык эшчәнлегендә, шулай ук «Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләре;

Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән, оборона, иминлек һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән;

Б) «Гражданнар тарафыннан бакчачылык һәм яшелчәчелек алып бару турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 29 июлендәге 217-ФЗ номерлы Федераль законда каралган гомуми билгеләнештәге җир кишәрлекләренә карата шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык яисә яшелчәчелек алып бару өчен сатып алынган (бирелгән) җир кишәрлекләренә карата 0,1 процент;

В) мәгариф, фән, сәламәтлек саклау һәм социаль тәэмин итү, физик культура һәм спорт, сәнгать объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата 0,1 процент;

Г) башка җир кишәрлекләренә карата 1,5 процент;»;

**Б)** 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. 100% күләмендә җир салымын түләүдән азат итү рәвешендә салым льготалары бирү:

А) ялгыз яшәүче 85 яшьтән өлкәнрәк гражданнар;

Б) ятим балалар;

В) стихияле бәла-казалардан зыян күргән гражданнар;

Г) Бөек Ватан сугышы ветераннары һәм инвалидлары, шулай ук сугыш хәрәкәтләре ветераннары һәм инвалидлары;

Д) оешмаларга һәм учреждениеләргә - зиратлар, үләт базлары, граждан күмүләре, каты көнкүреш калдыклары полигоннары биләгән җир кишәрлекләренә карата;

Е) янгын күзәтчелеге һәм ирекле янгын сүндерүчеләр иҗтимагый берләшмәләре әгъзалары;

Ж) халыкны су белән тәэмин итү өчен скважиналар һәм су җыю башнялары урнаштырылган җир кишәрлекләре; муниципаль милектәге гидротехник корылма һәм плотиналар; су җыю челтәре каптажын реконструкцияләү өчен; Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районы авыл җирлеге территориясендә урнашкан коммуналь хезмәт күрсәтү өчен;

З) муниципаль учреждениеләргә - әлеге карарның 2 пунктының А пунктчасында күрсәтелгән, яр буе, мәдәният һәм ял парклары, аллеялар, скверлар, спорт мәйданчыгы, спорт паркы, балалар мәйданчыгы, тренажер мәйданы булган гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата;

И) Теләче муниципаль районы Советы карары нигезендә төзелгән муниципаль дәрәҗәдәге сәнәгать парклары яисә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары нигезендә төзелгән индустриаль (сәнәгать) парклар биләгән җир кишәрлекләре, милекчеләр җир кишәрлеген, резидентларны җир участогына эшчәнлек алып бару өчен җәлеп иткән очракта, башка очракларда җир салымыннан азат итү кулланылмый.»;

**В)** 3.1 һәм 3.2 пунктларын төшереп калдырырга

**Г)** 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Салым чоры дип календарь ел танылa дип билгеләргә.

рөхсәт ителгән файдалануның бер төре булган җир кишәрлегенә карата әлеге кишәрлек өчен билгеләнгән рөхсәт ителгән файдалану төрләре буенча җир салымы ставкасының иң зур күләмен билгеләргә.»;

Д) 4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.1. Салым түләүчеләргә - оешмаларга карата салым түләү һәм салым буенча салым түләү тәртибен һәм вакытын билгеләргә:

- салым түләүче оешмалар өчен салым түләү узган хисап кварталыннан соң икенче айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, беренче, икенче һәм өченче квартал узгач, җир салымы суммасының процент ставкасы күләмендә аванс түләүләре белән башкарыла.

Салым чоры йомгаклары буенча түләнергә тиешле салым суммасы үткән салым чорыннан соң килүче елның 15 февраленнән дә соңга калмыйча түләнә.»;

Е) 4.2 пунктын төшереп калдырарга.

2. Әлеге карар, 2025 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган 1 пунктның Д пунктчасыннан тыш, гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.

Авыл җирлеге башлыгы М.А.Валиуллин